АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«17» апрель 2023 ел № 12

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында

«Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин булган вазифа бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге № 650 Указына ярашлы рәвештә боеру:

1. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында кушымтадагы Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

Татарстан Республикасының
инвестицион үсеш агентлыгы
боерыгы белән расланган
____17.04.2023_________ №_12___

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - граждан хезмәткәрләре, Агентлык), аларга карата Агентлык җитәкчесе эшкә алучының вәкиле буларак, вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен регламентлаштыра.

2. Хәбәр граждан хезмәткәрләре тарафыннан язма рәвештә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында, шундый хәл турында белгәч, әлеге Нигезләмәдә Кушымтада китерелгән форма буенча белдерү рәвешендә төзелә (алга таба - белдерү) һәм Агентлык җитәкчесенә җибәрелә.

3. Агентлык җитәкчесе мондый белдерү килгән көннән башлап, дүрт эш көне дәвамында ришвәтчелек һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба - җаваплы зат) алдан карау өчен белдерү җибәрә.

4. Гаризаларны теркәү өчен җаваплы зат вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында гаризаларны исәпкә алу журналын алып бара.

5. Белдерүне алдан карау барышында җаваплы зат белдерү җибәргән граждан хезмәткәреннән анда әйтелгән шартлар буенча аңлатмалар алырга, билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга сораулар җибәрергә, шулай ук "Посейдон" ришвәтчелеккә каршы тору өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланырга хокуклы, шул исәптән сорауларны юнәлтү өчен.

6. Белдерүне алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат мотивацияле нәтиҗә әзерли. Алдан карау барышында алынган белдерү, нәтиҗә һәм башка материаллар җаваплы зат белдерүне алганнан соң җиде эш көне эчендә Агентлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия рәисенә тапшырыла (алга таба - Комиссия).

7. Әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән сораулар җибәрелгән очракта, белдерү, нәтиҗә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан Комиссия рәисенә белдерү алынганнан соң 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок Комиссия рәисе тарафыннан 30 көннән дә артык түгел озайтылырга мөмкин.

8. Белдерү, нәтиҗә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Агентлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт

тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Агентлыкның 15.02.2016 № 13-2/2лс боерыгы белән расланган Нигезләмә нигезендә карала.

**Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә**
**Кушымта**

Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенә

______________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы булганда), алган вазифа)

**Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында**
**БЕЛДЕРҮ**

Мин үземнең вазыйфаи бурычларымны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килүе турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксынуның барлыкка килүенә нигез булган шартлар: ______________________________________________________________________

Шәхси кызыксыну тәэсир иткән яки тәэсир итә алган эш бурычлары: ______________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителгән чаралар:____________________________________________________________,

Әлеге белдерүне караганда Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга телим/теләмим (кирәклесен ассызыкларга).

"___"____________ 20__ ел

______________________________________________
(белдерү җибәрүченең имзасы (имзаның расшифровкасы))